Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«18» ноябрь 2019 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге Фома авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елда Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге Фома авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан кала, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы рәвештә карап тоту һәм грунт-вак таш түшәү; су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару.

Халык җыены рәисе: Р.Х.Абдрахманов

Фома авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Абдрахманов